ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.02.2021 г. Заинск № 93

**"Балигъ булмаган баланың акчалата кертемен алуга законлы вәкиленә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2020 елның 07 августындагы 338 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип тану турында**

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2020 елның 24 декабрендәге 7483 номерлы боерыгы, “Банкта яки башка кредит оешмасындагы счетта (кертемдә) булган, балигълык яшенә җитмәгән балага караган счетны ябу, акча чараларын алу, күчерү, тоту өчен беренчел рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында” 2020 елның 05 ноябрендәге под-1158/20 номерлы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының "Норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә алу турында" 2020 елның 24 декабрендәге 04/13-06/6572 номерлы хаты, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә алу турында» 2021 елның 04 гыйнварындагы 16/21 номерлы хаты нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. "Балигъ булмаган баланың акчалата кертемен алуга законлы вәкиленә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2020 елның 07 августындагы 338 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында урнаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә “Банкта яки башка кредит оешмасындагы счетта (кертемдә) булган, балигълык яшенә җитмәгән балага караган счетны ябу, акча чараларын алу, күчерү, тоту өчен беренчел рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында” 2020 елның 05 ноябрендәге под-1158/20 номерлы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгын Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

юрист
И.П.Фәттахова
7-12-31